УДК

# ИБРАҺИМ БИККОЛОВ ПУБЛИЦИСТИКАСЫНДА XX ГАСЫР БАШЫ МӘДӘНИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫ ЧАГЫЛЫШЫ

**Сэйфулина Флера Сәгыйтовна**

*Казан (Идел буе) федераль университеты, Казан шәһ., Россия Федерациясе*

*e-mail: fsaifulina@mail.ru*

**Аннотация.** Статья посвящена анализу публицистики известного журналиста, общественного деятеля начала XX века – Ибрагима Биккулова (1884-1938), в публицистике которого во всем многообразии находит отражение культурно-общественная жизнь татар данного периода. Родившись в семье известных богословов Биккуловых (в деревне Новые Тинчали Буинского района РТ) в конце XIX столетия, Ибрагим, как и многие известные личности этого сложного периода, проходит яркую жизнь, посвященную делу служения своему народу. Его основная журналистская деятельность, где находят отражение яркие страницы истории татарского народа, приходится к противоречивому периоду в истории становления татарской нации, советского государства.

**Ключевые слова:** Татарская литература начала XX в., журналистика, публицистика, Ибрагим Биккулов.

# CULTURAL AND SOCIAL LIFE OF THE EARLY 20th CENTURY IN IBRAHIM BIKKULOV’S PUBLICISM

**Sayfulina Flera Sagitovna**

*Kazan Federal University, Kazan, Russia*

*e-mail: fsaifulina@mail.ru*

**Abstract.** The article analyzes the publicism of the famous journalist, public figure of the early 20$^{th}$ century Ibrahim Bikkulov (1884-1938). Cultural and social life of the Tatars of this period is reflected in his work. He was born in the Bikkulovs

family, a family of well-known theologians (in the village Novye Tinchali in Buinsk district of Tatarstan Republic) at the end of the 19th century. Ibrahim, like many well-known personalities of those difficult times, had a bright life dedicated to the service of his people. His main activity lasted in a controversial period of the Tatar nation and the Soviet state formation. The bright sides of the history of the Tatars are reflected in his publicism.

**Key words:** Tatar literature of the early 20th century, journalism, publicism, Ibrahim Bikkulov.

Бикколов Ибраһим Җамаледдин улы (1884-1938) – җәмәгать эшлеклесе, педагог, XX гасыр башында актив әдәби-публицистик эшчәнлек алып баручы журналист, тәрҗемәче. Әдәбиятка бертуган Касыйм һәм Ибраһим Бикколовларны биргән әлеге атаклы нәсел хакында Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» китабының «Шәхесләр һәм истәлекле вакыйгалар» [1, с. 283] өлешендә, Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар» [1, с. 136] китабында шактый тәфсилле мәкаләләр багышланган. Әлеге язмаларда Бабалары Габделлатыйф хәзрәтнең ата-анасы да заманының диндар, данлыклы гаиләләреннән чыккан булулары хакында языла һәм Ш. Мәрҗани гаиләсе белән туганлык бәйләнеше дә күрсәтә.

И. Бикколов Казанда атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала, монда уку елларында Ф. Әмирхан белән якыннан таныша. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә Ф. Әмирхан җитәкчелегендә оештырылган әдәбият түгәрәге эшендә дә И. Бикколовның катнашуы, Казанда татар шәкертләре тарафыннан оештырылган «Ислахчылар» хәрәкәтендә дә (1905-1906) актив эшчәнлек алып баручылар буларак та Ф. Әмирхан һәм И. Бикколов исемнәре янәшә телгә алына. [3, С. 14-16].

Русиянең төрле төбәкләрендә яшәгән татарларга милли белем тарату уе белән янып яшәгән бер төркем яшьләр арасында «Мөхәммәдия»не тәмамлаган И. Бикколов та була, ул Себер шәһәрләренең берсе – Томскига мөгаллим булып

китә, 1906-1913 анда балалар укыта. И. Бикколовның журналистлык эшчәнлеге дә шушы елларда башлана.

Гасыр башы татар вакытлы матбугат битләрендә И. Бикколов имзасы белән басылган мәкаләләрне «Шура», «Мәктәп», «Аң», «Ак юл», «Сөембикә» журналларында күрергә мөмкин; үз чорының актуаль мәсьәләләрен күтәргән мәкаләләре белән ул «әл-Ислах», «Сибирия», «Йолдыз», «Ил» кебек гәзитәләрдә дә хезмәттәшлек итә.

Гасыр башы татат җәмгыяте үзәгендә кайнаган И. Бикколов эшчәнлегендә аның шул заман мәдәнияте торышына мөнәсәбәте ачык чагылыш таба. «Тукай «Әл-ислах» идарәсендә» дигән истәлегендә И. Бикколов Г. Тукай белән 1908 елның беренче яртысында танышуы хакында яза: «Тукай белән «Әл-ислах» идарәсендә таныштым һәм аның белән бик тиз дуслаштык, бергә эшли, бергә яза торган идек». [4, 2 апрель]. Г.Тукайның вафаты хакындагы хәбәрне И. Бикколов Себердә, Томскида ишетә. Икенче көнне үк «Сибирия» гәзитендә аның Тукайга мөнәсәбәтле мәкаләсе басылып чыга. [5, 7 апрель]. Мәкалә дустанә интонация, әлеге шәхескә рухи якынлык белән язылган булуы ягыннан игътибарны җәлеп итә. Журналист буларак Бикколов Тукай иҗатына, әсәрләренә тәфсилле бәя бирә. «Габдулла әфәнденең болай безне иртә ташлавы, аңарда киләчәктә бик зур өметләрнең булуы бу матәмне безгә ике өлеш авыр итәдер. Ул әле бик яшь, аңарда киләчәктә бик зур өметләр бар иде. ... Менә иң талантлы шагыйребезне, иң беренче әдибебезне дә югалттык. Хәзер безгә Габдулла әфәнденең Толстой хакында әйтдеке «Тәсбих өзелде» сүзләрен тәкърарлап, Гаяз, Әмирхан, Сәгыйтьләр вә Гафурилар кебек мөхтәрәм затларыбыздан төзелгән тәсбих өзелде, шушы тәсбихнең иң кыйммәтле бер төймәсе дә җиргә төшеп югалды, мәңге табылмаска югалды,- диеп тәкъдирнең бу каты золымына баш кына ияргә калды», - дип тәмамлана. Мәкаләдә авторының Г. Тукай шәхесенә, аның татар әдәбиятында тоткан урынына югары бәясе чагылыш таба.

Мәгълүматларга караганда, И. Бикколов 1913 ел ахырында Томскидан Казанга кайта. Аның бу еллардагы публицистик эшчәнлеге шактый киңкырлы

булуы күзгә ташлана. 1914-16 елларда вакытлы матбугат битләрендә И. Бикколовның гасыр башы татар әдәбияты үсеше, вакытлы матбугат торышы, илдәге сәяси һәм икътисадый тормыш хакында саллы, гомумиләштерү характерындагы мәкаләләре дөнья күрүе – аның бу чорда ук шактый җитлеккән, үз фикере һәм һәр мәсьәләгә үз карашы булган шәхес икәнлеген раслый. Шул вакытында ук аның бу өлкәдәге эшчәнлегенә Г. Ибраһимов тарафыннан “Яңа имзалар вә яшь куәтләр” [6, 29 апр] мәкаләсендә югары бәя бирелә.

И. Бикколовның 1914 елда басылган мәкаләләренең берсе - «Беренче мөгаллим» – И. Гаспралының вафаты уңаеннан язылган. «Шималь төрекләренең бу беренче мөгаллиме мөкәммәл Аурупа белемен алган, чын тәрбия вә гыйлем сахибе, чын мәгънәсе илә Аурупалы бер зыялы иде»,- дигән бәясе авторның әлеге шәхескә мөнәсәбәтен чагылдыра. [7, 14 сентябрь]. Монда И. Гаспралының эшчәнлегенә, татар милләте өчен кылган гамәлләренә югары бәя бирелә, аеруча мәкалә язган вакыттан 32 ел элек дөнья күрә башлаган «Тәрҗеман» гәзитен чыгаруының төрки-татар халкының тәрәккыятендә зур игътибарга лаеклы, авыр, ләкин бик кирәкле эш булуы күрсәтнлә. Мәкалә И. Гаспралы шәхесен танытуга, ул башкарган эшләрнең кыйммәтенә төшенергә, төрки халыкларның аңа карата булган мөнәсәбәтен күз алдына китерергә ярдәм итә.

И. Бикколовның мөхтәрәм Ш. Мәрҗанинең тууына йөз ел тулу уңаеннан үткәреләчәк чараларга әзерлек алып бару хакында язылган мәкаләсе “Мәрҗани юбилее мөнәсәбәте илә” [8, 14 сентябрь] дә шушы юнәлештә язылган. И. Бикколовның бу мәсьәләләрдә шактый эзлекле булуы икенче мәкаләсендә чагылыш таба. “Шималь төрекләренең каһарманы” [9, 9 гыйнвар] алда каралган мәкаләдә күтәрелгән мәсьәләнең нәтиҗәсе буларак язылган. Монда автор, юбилее уңаеннан Ш. Мәрҗани шәхесен ачу, аның исемен кабат искә алу, милләт өчен башкарган эшләренә югары бәя бирү юнәлешендә фикер йөртә. Мәкалә авторы Ш. Мәрҗанине яңарыш хәрәкәте башында торган галим буларак бәяли һәм «шушы вакыттан башлап, тик вә тыныч кына яткан шималь

төрекләре дөньясы хәрәкәткә килә һәм шушы хәрәкәт насыйры Гаспринский, Баруди вә Бигиләргә нигез хәзерлидер», - дип бәяли. Мәрҗани мәкаләдә әлегә кадәр Бохарага күз тотып эш иткән татар дөньясын Мисыр, Истанбул тарафларына һәм Рус мәдәнияты вә әдәбиятына юнәлтүче буларак бәяләнә. «Ул шималь (төньяк) төрекләре арасындагы фикри вә иҗтимагый инкыйлабны башлап калдыручы кешеләрдәндер. Аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә татарларда милли аң, милли әдәбият, милли тел, милли хыяллар белән яшәүче яшьләр җитеште», - дигән фикер әлеге мәкаләнең асыл эчтәлеген тәшкил итә. Шуның белән бергә И. Бикколов әлеге шәхес юбилеен тиешле дәрәҗәдә билгеләп үтергә мөмкинлек булмавы хакында ачынып яза.

Якын дусты, фикердәше Ф. Әмирхан иҗаты, гомумән, әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге хакында И. Бикколовның берничә мәкаләсе билгеле. Шуларның берсе – 1915 елда «Кояш»та басылган «Татарча театр» [10, 1915 февраль] дип аталган мәкаләсе Ф. Әмирханның «Тигезсезләр»енең беренче тапкыр сәхнәдә куелуына мөнәсәбәтле язылა. Мәкалә, бер яктан, әсәргә идея-эстетик кыйммәте ягыннан бәя бирергә омтылыш, икенче яктан бу фикернең сәхнәдә актерлар уены аша тормышка ашырылу дәрәҗәсен бәяләү юнәлешендә булуы белән игътибарга лаеклы. Мәкалә авторы шушы вакыйганы журналистлык төгәллеге белән чагылдыра, шул исәптән замана атмосферасын тудыра, театр сәнгатенең үзенчәлекләрен исәпкә алып, анализ-бәяләмә дә бирә. Мәкаләнең төп өлешен, әсәрнең сәхнәдә куелышы һәм сәхнә шартларында идея-эстетик мәгънәсенең ачылу дәрәҗәсен бәяләү алып тора. Монардан тыш И. Бикколовның «Фатих Әмирхан турында истәлекләр» [11, 192] китабына кертелгән «Бөек язучы Фатих Зариф угылы Әмирхан» мәкаләсендә аның иҗтимагый эшчәнлегенә, дөньяга карашларының формалашуында, язучы булып җитлегүендә әһәмиятле урын тоткан мәдрәсә чорына, иҗатына шактый җитди бәя бирелә. «Мәрхүмнең авыруы» мәкаләсе язучының соңгы көннәре хакында бәян итә. И. Бикколов мәрхүмне озату мәрасимен башлап йөри, классик язучының тәрҗемәи хәле турында чыгыш ясый, калган кульязмаларын җыештырып, тәртипкә салып куючы да ул була.

И. Бикколовның үз заманы әдәби барышына багышлап язылган аналитик мәкаләләре аерым игътибарга лаек. Аның 1916 елда «Аң» [12, № 1] журналында татар вакытлы матбугатының тууына 10 ел тулу уңае белән дөнья күргән мәкаләләсе бу өлкәдәге унъеллык тәҗрибәгә нәтиҗә ясау, йомгаклау рухындагы язма. Әлеге мәкаләдә автор үткән дистә ел эчендә татар телендә чыга торган һәм чыгудан тукталган газета-журналларга күзәтү ясый, белешмә бирә. Бу факт И. Бикколовның актив хәбәрче, вакытлы матбугат үсешен күзәтеп баручы, нәтиҗәләр ясый алырлык аналитик фикер йөртүче публицист булуы хакында сөйли.

1917-1918 елларда И. Бикколов Сембер (Ульяновск) шәһәрендә «Җөмһүрият» дип аталган атналык газета редакторы була. (Бу гәзиттә шул вакыттагы илнең, татарларның, Сембернең дини, сәяси барышын күзәткән «Милли мохтарият мөнәсәбәте илә», «Учредительный Собраниягә сайлаулар тирәсендә», «Милли мөхтәрият эше» кебек мәкаләләр, эчке һәм тышкы яңалыклар һ.б. бастырылган. И. Бикколов Сембер губернасы вәкиле буларак Уфада үткән «Милләт мәҗлесе» эшендә катнашуы, «Милләт мәҗлесе»нең «Хокук комиссиясе» әгъзасы итеп сайлануы да билгеле).

И. Бикколовның XX гасыр башындагы гомум Русия өчен катлаулы булган вакыйгаларга мөнәсәбәтен белдереп язылган, аны җитди сәяси журналист итеп таныткан мәкаләләре дә шактый. Бу җәһәттән аның 1914 елгы эшчәнлеген күрсәтергә мөмкин. «Петербургта мөселман съезды», «Гомумауропа сугыш алдында», «Бөтен дөнья сугыш алдында» мәкаләләрендә авторның әлеге вакыйгаларга мөнәсәбәте чагылыш таба. Язмалар И. Бикколовның татар дөньясы, яки Русия вакыйгаларыннан гына түгел, ә гомумтөрки һәм ауропа илләрендәге сәяси вакыйгаларндан да хәбәрдар булган киң колачлы, аналитик фикерле журналист булуын раслый.

Алдынгы карашлы рухани гаиләсендә тәрбияләнеп, ике гасыр арасы кебек катлаулы чорда үз эшчәнлеген укытучы эшеннән тыш, журналист, публицист буларак та билгеләгән, шушы юнәлештә шактый күләмле хезмәтләр калдырган Ибраһим Бикколовның XX гасыр башы татар милли хәрәкәтендә,

иҗтимагый тормышында, вакытлы матбугат үсешендә тоткан урыны гаять зур, әһәмиятле дип билгели алабыз. Бу юнәлештәге башкарган эшебез төгәлләнгән булуга дәгъва итми. Исеме үз заманы татар җәмәгатьчелегенә шактый киң мәгълүм булган укытучы, шул заман әдәби барышының асылын тәшкил иткән әдипләр белән бергә кулына каләм алган, соңрак шәхес культы корбаны булган И. Бикколовның әлеге чор вакытлы матбугаты битләрендә дөнья күргән публицистик мирасын барлау, аны үз заманы әдәби торышы кысаларында тәфсилләп өйрәнү, һичшиксез, дәвам иттерелергә тиеш.

**Әдәбият**


1. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. – 415 б.
2. Фәхреддин Р. Асар. – Казан: Рухият, 2010. – Б.136.
3. Бертуган Бикколовлар. Әдәби-биографик җыентык / Төзүче-авт. Ф.Сәйфуллина, И.Гомәров h.б. – Казан: Җыен, 2016. – 448 с.
4. Бикколов И. Тукай «Әл-Ислах» идарәсендә // Ак юл. – 1914. – 2 апрель (№ 24).
5. Бикколов И. Габдулла әфәнде Тукаев // Сибирия. – 1913. – 7 апр. (№ 96).
6. Ибраһимов Г. Яңа имзалар вә яшь куәтләр // Йолдыз. – 1915. – 29 апр.
7. Бикколов И. Беренче мөгаллим // Кояш. – 1914. – № 509. – 14 сентябрь.
8. Бикколов И. Мәрҗани юбилее мөнәсәбәте илә // Кояш. – 1914. – 18 сентябрь.
9. Бикколов И. Шималь төрекләренең каһарманы // Кояш. – 1915. – 9 гыйнвар.
10. Бикколов И. Татарча театр // Кояш. – 1915. Февраль.
11. Фатих Әмирхан турында истәлекләр / Төз. Ф. Ибраһимова, Р. Әмирхан. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. – 192 б.
12. Бикколов И. Вакытлы матбугатымызның әүвәлге ун елы // Аң. – 1916. – № 1.